КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 24 август г.Казань № 1016

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 28 июнь, 443 нче карары белән расланган Мәгълүмат-коммуникация технологияләре өлкәсендә элемтә чараларының һәм хезмәт күрсәтүләренең, программа белән тәэмин итүнең, челтәр җиһазларының һәм аерым матди-техник ресурсларның исемлегенә, сан нормативларына, куллану үзенчәлекләренә һәм характеристикаларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Товарларның, эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең аерым төрләренә, товарларның, эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең саны, исемлекләре һәм нормативлары, аларның куллану сыйфатлары таләпләрен һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасының бюджеттан тыш дәүләт фондлары белән идарә органнары һәм аларның территориаль органнары, казна һәм бюджет учреждениеләре буйсынуындагы органнар һәм дәүләт унитар предприятиеләре функцияләрен алар тарафыннан товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләрнең аерым төрләрен сатып алганда аларның аерым төрләрен сатып алуга кулланыла торган башка характеристикаларын билгеләү кагыйдәләрен раслау турында» 2017 ел, 28 июнь, 443 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 24 апрель, 521 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Мәгълүмат-коммуникация технологияләре өлкәсендә элемтә чараларының һәм хезмәт күрсәтүләренең, программа белән тәэмин итүнең, челтәр җиһазларының һәм аерым

матди-техник ресурсларның исемлегенә, сан нормативларына, куллану үзенчәлекләренә һәм характеристикаларына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.6.1 пунктның 4 графасында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

1.7.1 пунктның 4 графасында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин